з

Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

__25.10.2025___

Менделеевск ш.

№ __659/1____

2040 елга кадәр “Менделеевск шәһәре"
муниципаль берәмлеген җылылык
белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән
схемасын раслау турында

Россия Федерациясенең «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 8 августындагы 808 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларны эшләү тәртибе турында» 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карарлары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2040 елга кадәр “Менделеевск шәһәре”н җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын кушымта нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» Башкарма комитетының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында 2014 елның 7 октябрендәге 12 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм «Менделеевск шәһәре»н җылылык белән тәэмин итү схемасын билгеләнгән тәртиптә Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Ф.Искаков